**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 31 декабрь № 1088

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2015 ел, 7 декабрь, 922 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2015 ел, 7 декабрь, 922 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 11 май, 295 нче; 2016 ел, 22 июнь, 426 нчы; 2016 ел, 21 июль, 492 нче; 2016 ел, 29 август, 598 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 995 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган дәүләт хезмәте күрсәтүгә турыдан-туры бәйле норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентларында:

4 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган стационар, ярымстационар формалы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында дәүләт хезмәте күрсәтүгә гомумхуҗалык ихтыяҗларына норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентларында:

1.16 нчы пунктта «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мамадыш картлар һәм инвалидлар махсус интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләрен «Мамадыш картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган стационар формалы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында койка-көннәр санында:

«Мамадыш муниципаль районы» юлы буенча «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мамадыш картлар һәм инвалидлар махсус интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләрен «Мамадыш картлар һәм инвалидлар интернат йорты» ДАСХКУ» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2016 елның 16 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\1088.doc